ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясына үзгәреш кертү турында» 398-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясына үзгәреш кертү турында» 398-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмmәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1902-VI ДС

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясына үзгәреш кертү турында

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$135^5$ статья. **Аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык белән шөгыльләнүче физик затлар арасында бүлү тәртибе**

1. Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык итүче физик затларга (алга таба - аучылар) аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне бирү аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла.

2. Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләр аучылар арасында аучылык ресурсларын аулауга квота, аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт ителгән нормалар, һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләренә мөнәсәбәттә билгеләнгән үткәрү мөмкинлеге нормалары чикләрендә бүленә.

3. Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне аучылар арасында бүлү һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне алуга гаризалар керү чираты тәртибендә гамәлгә ашырыла, Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органының норматив хокукый акты белән расланган аучылык ресурслары исемлегенә кертелгән, аларны аулауга рөхсәтләрне бүлү шобага салу юлы белән гамәлгә ашырыла торган аучылык

ресурсларын аулауга рөхсәтләрдән тыш. Аучылык ресурсларын әлеге өлештә күрсәтелгән исемлеккә кертү аучылык ресурсларын аулауга квота, аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт ителгән нормалар, һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләренә мөнәсәбәттә билгеләнгән үткәрү мөмкинлеге нормаларыннан чыгып башкарыла.

4. Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләр алуга гаризалар бирү, әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән аучылык ресурсларыннан тыш, аучылык ресурсларының тиешле ау төрләре яки төркеменә ау сезоны ачылган көнгә кадәр 10 календарь көн алдан башлана һәм мондый ау сезоны беткән көнгә кадәр дәвам итә. Гариза бирү башланган көн ял яки бәйрәм көненә туры килгән очракта, гариза бирү ял яки бәйрәм көненә кадәр булган көнне башлана.

5. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне бүлү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына жшобага салуда катнашу өчен гаризалар биргән аучылар арасында шобага салу юлы белән башкарыла.

6. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы шобага үткәрү урынын, датасын һәм вакытын, һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга шобага үткәрү юлы белән бирелә торган рөхсәтләр санын (аучылык ресурслары төрләре буенча һәм муниципаль берәмлекләр буенча), шобагада катнашу өчен 10 календарь көненнән дә ким булмаска тиешле гаризалар бирү вакытын билгели, һәм күрсәтелгән мәгълүматны шобагада катнашу өчен гаризалар кабул итә башлау датасына кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында урнаштыра. Шобага үткәрү датасы аның нәтиҗәләре буенча аучылык ресурсларының тиешле төрләрен яки төркемнәренә ау сезоны ачылуга ким дигәндә 10 календарь көн кала Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга гаризалар бирү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

7. Аучылык ресурсларының һәр төре буенча бер аучы шобага салуда катнашу өчен бер гариза гына бирә ала. Шобага салуда катнашу өчен гаризада күрсәтелә:

1) аучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны (тору, фактта яшәү), элемтә өчен телефоны, аучылык билеты турында белешмәләр (серия, номер һәм бирелү датасы);

2) һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләре аның чикләрендә урнашкан, аучы шул территориядә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга дәгъва иткән бер муниципаль берәмлек атамасы;

3) аучылык ресурсларының төре;

4) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

8. Шобага салуда катнашуга гариза формасы Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы тарафыннан раслана.

9. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы шобага салуда катнашу өчен

гаризаларны һәм андагы мәгълүматларны, шулай ук шобага салуда катнашу өчен гаризаларны тапшыруның билгеләнгән срогы үтәлешен тикшерә һәм шобагада катнашу өчен гариза кергән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча гариза бирүчене шобага салуда катнаштыру яки шобага салуда катнаштырудан баш тарту турында карар кабул итә.

10. Шобага салуда катнашудан баш тарту нигезләре булып тора:

1) әлеге статьяның 7 һәм 8 өлешләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

2) аучы биргән мәгълүматларның дөрес булмавы фактын билгеләү;

3) шобага салуда катнашуга гаризалар бирүнең билгеләнгән срогын үтәмәү.

11. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы аучылык ресурслары төрләре һәм муниципаль берәмлекләр буенча шобага салуда катнашырга рөхсәт ителгән аучылар исемлеген, шулай ук шобага салуда катнашуга рөхсәт бирелмәгән аучылар исемлеген формалаштыра, аларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында шобага салуда катнашу өчен гаризалар бирү срогы тәмамланырга өч календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыра һәм аларны алдагы һәр эш көнендә кимендә бер тапкыр актуальләштерә. Йомгаклау исемлекләре шобага салуда катнашу өчен гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

12. Шобага Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә төзелә торган комиссия тарафыннан үткәрелә. Комиссия составына җәмәгатьчелек вәкилләре кертелә.

13. Шобага мәгълүмати системаларны (электрон сервислар) кулланып очраклы саннар генерациясе ысулы белән, яисә номерлар белән конвертлар (контейнерлар) урнаштырыла торган лототрон кулланып үткәрелә. Шобага гавами рәвештә үткәрелә, аны уздырганда аучылар, аларның вәкилләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга мөмкин.

14. Шобага нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелә, ул шобага үткәрүдә катнашкан барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәдә күрсәтелә:

1) һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукын алган аучылар (аучылык ресурсларының төрен һәм муниципаль берәмлекне күрсәтеп);

2) әлеге статьяның 17 һәм 18 өлешләрендә билгеләнгән очракларда һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукын алырга мөмкин булган аучылар (һәр муниципаль берәмлектә аучылык ресурсларының һәр төре буенча кимендә биш зат), шобага үткәргәндә билгеләнгән чиратны күрсәтеп.

15. Шобага салу нәтиҗәләре турында мәгълүмат Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында шобага салынган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

16. Шобага нәтиҗәләре буенча һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу өчен, әлеге статьяның 14 өлешендәге
1 пунктында күрсәтелгән аучылар, һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга гариза белән Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органына Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында шобага нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән соңгы 10 эш көне эчендә мөрәҗәгать итәләр.

17. Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы әлеге статьяның 14 өлешендәге 14 пунктында күрсәтелгән аучылар тарафыннан әлеге статьяның 16 өлешендә билгеләнгән срокта гамәлгә ашырылмаган очракта, һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы әлеге статьяның 14 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән затларга чират тәртибендә күчә.

18. Аучылык сезоны дәвамында квоталар, аучылык ресурсларын аулау нормалары, һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләренең үткәрү мөмкинлеге нормалары, һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт ителгән нормативлар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә арттырылган очракта һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы әлеге статьяның 14 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән аучыларга чиратлылык тәртибендә бирелә.

19. Әлеге статьяның 14 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән аучыларга һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга хокук барлыкка килү турында мәгълүмат Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

20. Әлеге статьяның 17 һәм 18 өлешләрендә каралган очракларда һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга хокук мондый хокук барлыкка килү турындагы мәгълүмат Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган көннән 10 эш көне дәвамында гамәлдә була.

Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга хокуклары барлыкка килгән аучылар һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу өчен һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга гариза белән Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органына әлеге өлештә билгеләнгән срокта мөрәҗәгать итәләр.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясына үзгәреш кертү турында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга гаризалар бирә башлау вакытын билгеләү, һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык белән шөгыльләнүче физик затлар арасында аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне бүлү процедурасын камилләштерү, шул исәптән аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт бирүнең электрон мәгълүмат системаларын кулланып, очраклы рәвештә сайлап алу (шобага салу) аша башкарыла торган процедурасын цифрлаштыруны кертү максатларында эшләнде.

«Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясындагы 6 өлеше нигезендә (алга таба – аучылык турында Федераль закон) һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык белән шөгыльләнүче физик затлар арасында аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне бүлү тәртибе Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә дип карала.

Мондый тәртип Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясында билгеләнгән. Әмма ул рөхсәт бирүдә мәгълүмат системалары һәм электрон сервислар куллану мөмкинлеген күздә тотмый.

Аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне бүлү процедурасын автоматлаштыру өлешендә Биологик ресурслар буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетының мәгълүмат системасын модернизацияләү буенча эш алып барылуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Экология кодексына тиешле үзгәрешләр кертү таләп ителә.

Шулай ук гамәлдәге тәртип аучылык ресурсларының рөхсәт исемлеген коррупция куркынычын юкка чыгаручы иң гадел ысул булган шобага салу юлы белән чикли. Тәкъдим ителгән төзәтмәләр аучылык ресурсларының мондый исемлеген арттырырга мөмкинлек бирә.

Россия Федерациясе Табигый байлыклар һәм экология министрлыгының 2014 елның 29 августындагы 379 номерлы боерыгы белән расланган аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне бүлү өчен кирәкле заявкалар һәм гаризалар бирү тәртибенең 3.1 пункты белән алдагы ау сезонына һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылыкка рөхсәт алуга гаризалар бирә башлау срогы аучылык турында Федераль законның 31 статьясындагы 6 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнергә мөмкин дип карала һәм ау срогының Россия Федерациясе субъектында билгеләнгән вакытына кадәр 10 календарь көннән дә ким булмаска тиеш. Мондый срокны билгеләү аучылык ресурсларын аулау өчен рөхсәтне ул еллар эчендә түбәндәгеләр булырга мөмкин булган берничә елга алдан алудан сакланячак:

- ауга чикләүләр кертелү;
- ау сроклары үзгәрү;
- аучылык биләмәләрен һәркем өчен мөмкин булган җирләрдән беркетелгән җирләргә күчерү.

Аучыларның 80 проценты рөхсәт бирә башлауның беренче көннәрдә үк рөхсәт алуны истә тотып, рөхсәт алуга гаризалар кабул итә башлау вакытын аучылык ресурсларының тиешле төрләренә һәм төркемнәренә аучылык чоры башланганчы 10 календарь көн дип билгеләү максатка ярашлы.

Законны кабул итү һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга гаризалар бирү срогын билгеләргә ярдәм итәчәк, һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык белән шөгыльләнүче физик затлар арасында аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне бүлү процедурасын камилләштерергә мөмкинлек бирәчәк, шул исәптән заманча цифрлы технологияләр һәм электрон мәгълүмат системаларын куллану нигезендә.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының «Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылыкны гамәлгә ашыручы физик затлар арасында кыргый тояклы хайваннарны атуга рөхсәт бирү комиссиясен төзү турында» 2018 елның 24 июлендәге 192-од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертүне, шулай ук күрсәтелгән орган тарафыннан һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә ауга рөхсәт бирү шобага салу юлы белән гамәлгә ашырыла торган аучылык ресурсларын раслауны һәм һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт бирү буенча шобага салуда катнашуга гариза формаларын раслауны таләп итә.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^5$ статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.